ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 сентябрь 2015 ел № 5481

Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектларына адреслар бирү, аларны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында

«Федераль мәгълүмати адрес системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ санлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 бүлек, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адреслар бирү, аларны үзгәрү һәм гамәлдән чыгару турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 санлы Карарының 4 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турындагы нигезнамәнең 5.28 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектларына адреслар бирү, аларны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2007 елның 9 ноябрендә «Челнинские известия» газетасының 213-215 саннарында басылып чыккан Башкарма комитет Җитәкчесенең «Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектларына адреслар бирү (үзгәртү һәм гамәлдән чыгару) тәртибе турындагы нигезнамәне раслау турында» 2007 елның 30 октябрендәге 4151 нче карары;

2) Башкарма комитет Җитәкчесенең «Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектларына адреслар бирү (үзгәртү, гамәлдән чыгару) тәртибе турындагы нигезнамәне раслау турында» 2007 елның 30 октябрендәге 4151 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 14 гыйнварындагы 65 нче карары.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Д.В. Щербага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2015 елның 25 сентябрендәге
5481 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектларына адреслар бирү, аларны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Кагыйдәләр, адрес структурасына карата таләпләрне кертеп, Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектларына адреслар бирү, аларны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибен билгели.

2. Әлеге Кагыйдәләрдә файдаланыла торган төшенчәләр түбәндәгеләрне аңлата:

«адрес барлыкка китерә торган элементлар» – ил, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек, торак пункт, урам-юл челтәре элементы, планлаштыру структурасы элементы һәм адресация объектының идентификация элементы (элементлары);

«адресация объектының идентификация элементлары» – җир участогының номеры, биналарның (корылмаларның), бүлмәләрнең һәм төзелеше тәмамланмаган объектларның типлары һәм номерлары;

«дәүләт адрес реестрында адресация объектының уникаль адрес номеры» дәүләт адрес реестрында адресация объекты адресына бирелә торган язу номеры;

«планлаштыру структурасы элементы» – зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), коммерциясез бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләрен урнаштыру территорияләре;

«урам-юл челтәре элементы» – урам, проспект, тыкрык, яр буе, мәйдан, бульвар, ябык тыкрык, тощү юлы, шоссе, аллея һәм башкалар.

3. Адресация объектына бирелгән адрес түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

1) уникальлек. Адресация объектының гамәлдән чыгарылган адресына алмашка бер үк адресны кабат яңа адресация объектына бирү, шулай ук җир участогына һәм анда урнашкан бинага (корылмага) яки төзелеше тәмамланмаган объектка бер үк адресны бирү очракларыннан тыш, бер үк адрес бердән артык адресация объектына бирелергә тиеш түгел;

2) мәҗбүрилек. Һәр адресация объектына адрес әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелергә тиеш;

3) легитимлык. Адресация объектына адрес бирү, шул адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, шулай ук адресны дәүләт адрес реестрына кертү адресның хокукый нигезен тәэмин итә.

4. Адреслар биру, аларныүзгәртү һәм гамәлдән чыгару хак түләтмичә гамәлгә ашырыла.

5. Адресация объектлары булып бер яки берничә күчемсез милек объекты, шул исәптән жир участоклары, бинала‌р, корылмалар, бүлмәләр һәм төзелеше тәмамланмаган объектлар тора.

## II. Адресация объектына адрес биру, шул адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибе

6. Адресация объектына адрес биру, адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, федераль мәгълүмати адрес системасын файдаланып, билгеләнгән планлаштыру структурасы һәм билгеләнгән тәртиптә Яр Чаллы шәһәренең состав өлешләренең исемнәре булган территорияләрдә Яр Чаллы шәһәренең Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7. Адресация объектларына адреслар биру һәм шул адресларны гамәлдән чыгару үз инициативасы буенча яки әлеге Кагыйдәләрнең 27 һәм 29 пунктларында күрсәтелгән физик яки юридик затларның гаризалары нигезендә Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла. Адресация объектларының адресларын гамәлдән чыгару кадастр исәбен һәм күчемсез милекнең дәүләт кадастрын алып баруны гамәлгә ашыра торган органның күчемсез милек объектын кадастр исәбеннән төшерү турында, шулай ук «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль законның 27 маддәсе 2 өлегенең 1 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча күчемсез милек объектының кадастр исәбен гамәлгә ашырудан баш тарту турында мәгълүматы (дәүләт адрес реестрын алып барганда, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш тәртибендә бирелгән) нигезендә, Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла. Адресация объектларының адресларын үзгәртү адрес барлыкка китерә торган элементларга исемнәр биру турында, аларның исемнәрен үзгәртү һәм гамәлдән чыгару турында кабул ителгән карарлар нигезендә Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Адресация объектына адрес биру түбәндәгеләргә карата гамәлгә ашырыла:

1) жир участокларына карата:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, төзелгән һәм төзелергә тиешле территориягә мөнәсәбәтле территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләгән очракта;

«Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль законда билгеләнгән таләпләр нигезендә жир участогына карата, нәтижәдә, жир участогын дәүләт кадастр исәбенә куйганда, дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру өчен кирәкле әлеге жир участогы турындагы мәгълүматны үз эченә алган документларны әзерләү тәэмин итәлә торган эшләр башкарган очракта;

2) биналарга, корылмаларга һәм төзелеше тәмамланмаган объектларга карата:

бина яки корылма төзүгә рөхсәт биргән (алган) очракта;

«Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль законда билгеләнгән таләпләр нигезендә бинага, корылмага һәм төзелеше тәмамланмаган объектка карата, нәтиҗәдә, бинаны, корылманы һәм төзелеше тәмамланмаган объектны дәүләт кадастр исәбенә куйганда, дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру өчен кирәкле әлеге бина, корылма һәм төзелеше тәмамланмаган объект турындагы мәгълүматны үз эченә алган документларны әзерләү тәэмин ителә торган эшләр башкарган очракта (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә бина, корылма һәм төзелеше тәмамланмаган объект төзү яки аны реконструкцияләү өчен төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәгән очракта);

3) бүлмәләргә карата:

торак бүлмәне торак булмаган бүлмә яки торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерү максатында, Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән тәртиптә бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру проектын әзерләгән һәм рәсмиләштергән очракта;

«Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль законда каралган нигезләмәләр нигезендә бүлмәгә, шул исәптән башка бүлмәне (бүлмәләрне) үзгәртү нәтиҗәсендә барлыкка килгән бүлмәгә карата, дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру өчен кирәкле әлеге бүлмә турындагы мәгълүматны үз эченә алган документларны әзерләгән һәм рәсмиләштергән очракта.

9. Биналарга, корылмаларга һәм төзелеше тәмамланмаган объектларга адреслар биргәндә әлеге адреслар, чикләрендә тиешле биналар, корылмалар һәм төзелеше тәмамланмаган объектлар урнашкан жир участокларының адресларына туры килергә тиеш.

10. Бинага яки корылмага адрес бирелмәгән очракта, әлеге бинада яки корылмада урнашкан бүлмәгә адрес бирү бер үк вакытта әлеге бинага яки корылмага адрес бирү шарты белән гамәлгә ашырыла.

11. Күп фатирлы йортка адрес биргән очракта, бер үк вакытта анда урнашкан барлык бүлмәләргә дә адреслар бирү гамәлгә ашырыла.

12. Планлаштыру структурасы элементларына һәм урам-юл челтәре элементларына исемнәр биргәндә, аларның исемнәрен үзгәртү яки гамәлдән чыгару, адресация объектларының адресларын үзгәртү (карарлар Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә) дәүләт адрес реестрын алып бару тәртибе нигезендә, планлаштыру структурасы элементларына һәм урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү турындагы, аларның исемнәрен үзгәртү яки гамәлдән чыгару турындагы мәгълүматларны бер үк вакытта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт адрес реестрына урнаштырып гамәлгә ашырыла.

13. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен һәм исемнәрен үзгәрткәндә, адресация объектының адресын үзгәртү, дәүләт адрес реестрын алып барганда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш тәртибендә бирелә торган Россия Федерациясе муниципаль берәмлекләрнең дәүләт географик атамалар каталогы һәм дәүләт реестрындагы мәгълүмат нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Адресация объекты адресын гамәлдән чыгару түбәндәге очракларда башкарыла:

1) адресация объекты булудан туктаган очракта;

2) «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль законның 27 маддәсе 2 бүлегенең 1 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объектының кадастр исәбен гамәлгә ашыру кире кагылган очракта;

3) адресация объектына яңа адрес биргән очракта.

15. Адресация объекты булудан туктаган очракта адресация объекты адресын гамәлдән чыгару, «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль законның 24 маддәсе 4 һәм 5 бүлекләрендә күрсәтелгән адресация объекты турындагы мәгълүматларны дәүләт күчемсез милек кадастрыннан төшереп калдыру һәм гамәлдән чыгару очракларыннан тыш, әлеге адресация объектын кадастр исәбеннән төшергәннән соң гамәлгә ашырыла.

16. Әлеге объектка яңа адрес бирми торып, бер үк вакытта гамәлдәге адресация объекты адресын гамәлдән чыгару рөхсәт ителми.

17. Үзгәртеп корыла торган күчемсез милек объектлары булып торган адресация объектлары (үзгәртелгән чикләрдә саклана торган адресация объектларыннан тыш) адресларын гамәлдән чыгару үзгәртеп корыла торган әлеге күчемсез милек объектларын исәптән төшергәннән соң гамәлгә ашырыла. Үзгәртеп корыла торган күчемсез милек объектлары булып торган һәм үзгәртеп корылганнан соң үзгәртелгән чикләрдә саклана торган адресация объектларының адресларын гамәлдән чыгару һәм аларга кабат адрес бирү башкарылмый.

18. Күчемсез милек объекты булудан туктау сәбәпле бина яки корылма адресын гамәлдән чыгарган очракта, бер үк вакытта әлеге бинадагы яки корылмадагы барлык бүлмәләрнең дә адреслары гамәлдән чыгарыла.

19. Адресация объектына адрес биргәндә яки аның адресын гамәлдән чыгарганда Башкарма комитет түбәндәгеләргә бурычлы:

1) адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару мөмкинлеген билгеләргә;

2) адресация объекты урнашкан урынны тикшерүне үткәрергә (кирәк булган очракта);

3) әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән адрес структурасына карата таләпләр һәм тәртип нигезендә, адресация объектына адрес бирү яки аны гамәлдән чыгару турында яки адресация объектына адрес бирүдән яки аның адресын гамәлдән чыгарудан баш тарту турында карар кабул итәргә.

20. Адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару Башкарма комитетның адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турындагы карары белән расланa.

21. Башкарма комитетның адресация объектына адрес бирү турындагы карары түбәндәгеләр белән бер үк вакытта кабул ителә:

1) Башкарма комитет тарафыннан тиешле территориянең кадастр картасында яки кадастр планында адресация объекты булып торган җир участогының урнашу схемасын раслау;

2) Башкарма комитет белән Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә, адресация объектлары булып торган җир участокларын яңадан бүлү турында килешү төзү;

3) Башкарма комитет белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелгән территорияне үстерү турында килешү төзү;

4) территорияне планлаштыру проектын раслау;

5) адресация объекты төзү турында карар кабул итү.

22. Башкарма комитетның адресация объектына адрес бирү турындагы карары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

адресация объектына бирелгән адресны;

адрес бирү турында карар кабул итүгә нигез булып торган документларның реквизитлары һәм исемнәре;

адресация объектының урнашу урынына тасвирлама;

адресация объектын барлыкка китерә торган күчемсез милек объектларының кадастр номерлары, адреслары һәм алар турында мәгълүматлар;

дәүләт адрес реестрында адресация объектының гамәлгә чыгарыла торган адресы һәм адресация объектының гамәлдән чыгарыла торган уникаль номеры (адресация объектына яңа адрес бирелгән очракта);

вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән башка кирәкле мәгълүматлар.

дәүләт кадастр исәбенә куелган күчемсез милек объектына адрес биргән очракта. Башкарма комитетның адресация объектына адрес бирү турындагы карарында шулай ук адресация объекты булып торган күчемсез милек объектының кадастр номеры күрсәтелә.

23. Башкарма комитетның адресация объектының адресын гамәлдән чыгару турындагы карары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

адресация объектының гамәлдән чыгарыла торган адресы;

дәүләт адрес реестрында адресация объектының гамәлдән чыгарыла торган адресының уникаль номеры;

адресация объектының адресын гамәлдән чыгару сәбәбе;

адресация объектының кадастр номеры һәм адресация объекты булудан туктау сәбәпле адресация объектының адресы гамәлдән чыгарылган очракта аны кадастр исәбеннән төшерү датасы;

адресация объектына адрес бирү турындагы карарның реквизитлары һәм адресация объектының адресы гамәлдән чыгарылган очракта, әлеге адресация объектына яңа адрес бирү нигезендә адресация объектының кадастр номеры;

Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән башка кирәкле мәгълүматлар.

Адресация объектына яңа адрес бирелгән очракта, адресация объектының адресын гамәлдән чыгару турындагы карар, Башкарма комитет карары буенча, әлеге адресация объектына яңа адрес бирү турындагы карар белән берләштерелергә мөмкин.

24. Башкарма комитетның адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турындагы карарлары федераль мәгълүмати адрес системасын файдаланып формалаштырылырга мөмкин.

25. Адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турындагы карар, ул кабул ителгәннән соң 3 эш көне эчендә мәҗбүри рәвештә Башкарма комитет тарафыннан дәүләт адрес реестрына кертелергә тиеш.

26. Адресация объектына адрес бирү, аның адресын үзгәртү яки гамәлдән

чыгару датасы булып адресация объектының адресы турындагы мәгълүматларны дәүләт адрес реестрына кертү датасы тора.

27. Адресация объектына адрес бирү турында яки аның адресын гамәлдән чыгару турында гариза (алга таба – гариза) шәхси инициатива буенча адресация объектының хуҗасы тарафыннан яисә адресация объектына карата түбәндәге хокукларның берсенә ия зат тарафыннан бирелә:

1) хуҗалык алып бару хокукы;

2) оператив идарә хокукы;

3) гомерлек варислык идарә хокукы;

4) даими (чикләнмәгән срокта) файдалану хокукы.

28. Гариза Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча әлеге Кагыйдәләрнең 27 пунктында күрсәтелгән затлар тарафыннан (алга таба – гариза бирүче) төзелә.

29. Гариза белән гариза бирүченең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч язуына нигезләнгән вәкаләтләр буенча эш итүче вәкиле (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Күп фатирлы йорттагы бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән гариза белән, әлеге милекчеләрнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән милекчеләрнең гомуми җыелышында кабул ителгән карары нигезендә әлеге гаризаны бирүгә вәкаләтләнгән вәкиле мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Гражданнарның коммерциясез бакчачылык, яшелчәчелек һәм (яки) дача берләшмәләренең әгъзалары исеменнән гариза белән, күрсәтелгән коммерциясез берләшмәләр әгъзаларының Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә әлеге коммерциясез берләшмәләр әгъзаларының гомуми җыелышында кабул ителгән карары нигезендә әлеге гаризаны бирүгә вәкаләтләнгән вәкиле мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

30. Гамәлдәге адресация объектын яки объектларын үзгәртеп кору нәтиҗәсендә 2 яки күбрәк адресация объектын үзгәртеп корган очракта, бер үк вакытта үзгәртеп корыла торган адресация объектлары өчен бер гариза бирелә.

31. Гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) тарафыннан Башкарма комитетка гаризага куелып салынган әйберләрнең исемлеге һәм аларны тапшыру турында белдерү язуы белән кәгазь йорткечтә почта аша җибәрелә, яки гариза бирүче тарафыннан шәхсән бирелә, яки «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә федераль мәгълүмати адрес системасы порталыннан (алга таба – адрес системасы порталы), гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, электрон документ формасында җибәрелә.

Гариза Башкарма комитетка яки адресация объекты урнашкан урын буенча күп функцияле үзәккә бирелә.

32. Гариза аны бирүче яки гариза бирүченең вәкиле тарафыннан имзалана.

Гариза бирүченең вәкиле тарафыннан гариза биргәндә, әлеге гаризага Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә рәсмиләштереп, гариза бирүченең вәкиленә бирелгән ышаныч язуы теркәлә.

Электрон документ формасындагы гариза кочәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып, гариза бирүче яисә гариза бирүченең вәкиле тарафыннан имзалана.

Гариза, гариза бирүченең вәкиле тарафыннан электрон документ формасында бирелгәндә, әлеге гаризага тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән һәм, кочәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып, ышаныч язуын биргән (имзалаган) зат тарафыннан имзаланган электрон документ формасындагы ышаныч язуы теркәлә (гариза бирүченең вәкиле ышаныч язуы нигезендә эш иткән очракта).

33. Гариза бирүче яки гариза бирүченең вәкиле гаризаны шәхсән мөрәҗәгать итеп биргән очракта, гариза бирүченең яки аның вәкиленең шәхесен раслаучы документ күрсәтелә.

Юридик зат исеменнән ышаныч язуыннан тыш эш итү хокукына ия зат үзенең шәхесен раслаучы документ күрсәтә һәм юридик затны дәүләти теркәү турында таныклыкның реквизитларын хәбәр итә, ә юридик затның вәкиле шулай ук әлеге юридик зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслаучы документны яки шул юридик зат җитәкчесенең имзасы һәм мөһере белән расланган әлеге документ күчермәсен күрсәтә.

34. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) адресация объектына (объектларына) хокук билгеләүче һәм (яки) хокукны раслаучы документлар;

2) үзгәртеп кору нәтиҗәсендә бер яки берничә адресация объектын барлыкка китерә торган күчемсез милек объектларының кадастр паспортлары (бер яки күбрәк яңа адресация объектын барлыкка китерә торган күчемсез милек объектларын үзгәртеп корган очракта);

3) адресация объектын төзүгә рөхсәт (төзелә торган адресация объектларына адрес биргәндә) һәм (яки) адресация объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт;

4) адресация объектының кадастр планында яки тиешле территориянең кадастр картасында урнашу схемасы (җир участогына адрес бирелгән очракта);

5) адресация объектының кадастр паспорты (кадастр исәбенә куелган адресация объектына адрес биргән очракта);

6) җирле үзидарә органының торак бүлмәне торак булмаган бүлмә яки торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерү турындагы карары (торак бүлмәне торак булмаган бүлмә яки торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерү нәтиҗәсендә бүлмәгә адрес биргән, әлеге адресны үзгәрткән һәм гамәлдән чыгарган очракта);

7) бер яки берничә яңа адресация объекты барлыкка китерә торган үзгәртеп төзү һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру вакытында кабул итү комиссиясенең акты (бер яки күбрәк яңа адресация объектын барлыкка китерә торган күчемсез милек объектларын (бүлмәләрне) үзгәртеп корган очракта);

8) исәптән төшерелгән күчемсез милек объекты турында кадастр өземтәсе (әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объектының адресын гамәлдән чыгарган очракта);

9) дәүләт күчемсез милек кадастрында адресация объекты буенча мәгълүматлар булмау турында белдерү язуы (әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объектының адресын гамәлдән чыгарган очракта).

35. Башкарма комитет дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар карамагында булган әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләрен, алардагы мәгълүматларны) алардан сорап ала.

Әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктында күрсәтелгән документлар дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар карамагында булмаган очракта, гариза бирүчеләр (гариза бирүченең вәкилләре) гариза биргәндә аларны теркәү хокукына ия.

Әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктында күрсәтелгән һәм электрон документлар формасында Башкарма комитетка тапшырыла торган документлар, көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып, гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) тарафыннан расланa.

36. Гариза һәм әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктында күрсәтелгән документлар Башкарма комитетка гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) тарафыннан шәхсән бирелгән очракта, Башкарма комитет гариза бирүчегә яки аның вәкиленә документлар исемлеген һәм кабул итү датасын күрсәтеп, документларны кабул итү турында расписка бирә. Расписка гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) әлеге документлар Башкарма комитет тарафыннан кабул итеп алынган көнне бирелә.

Әгәр гариза һәм әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктында күрсәтелгән документлар Башкарма комитетка почта аша җибәрелгән яки гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) тарафыннан шәхсән күп функцияле үзәк аша бирелгән булса, әлеге гаризаны һәм документларны кабул итеп алу турындагы расписка, Башкарма комитет тарафыннан документлар кабул ителгән көннең икенче эш көнендә, гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча Башкарма комитет тарафыннан җибәрелә.

Электрон документлар формасында тапшырылган гаризаны һәм әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итеп алу Башкарма комитет тарафыннан гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә), гаризаны һәм документларны (гаризаның керү-теркәү номеры, Башкарма комитет тарафыннан гаризаны һәм документларны кабул итеп алу датасы, электрон документлар формасында бирелгән файлларның күләме һәм исемнәренең исемлеге күрсәтелә) кабул итеп алу турында хәбәр җибәрү юлы белән раслана.

Гариза һәм документлар бердәм портал, региональ портал яки адрес системасы порталы аша җибәрелгән очракта, гаризаны һәм әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итеп алу турындагы хәбәр гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча яки федераль мәгълүмати адрес системасында гариза бирүченең (гариза бирүченең вәкиленең) шәхси кабинетына җибәрелә.

Гаризаны һәм әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итеп алу турындагы хәбәр, Башкарма комитетка гариза кергән көннән икенче эш көненнән дә соңга калмый гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) җибәрелә.

37. Адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турындагы карар, шулай ук адрес бирү яки аны гамәлдән чыгарудан баш тарту турындагы карар, гариза кергәннән соң 18 эш көненнән дә артмаган срокта. Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә.

38. Гариза күп функцияле үзәк аша бирелгән очракта әлеге Кагыйдәләрнең 37 пунктында күрсәтелгән срок, күп функцияле үзәк тарафыннан гаризаны һәм әлеге Кагыйдәләрнең 34 пунктында күрсәтелгән документларны (булган очракта) Башкарма комитетка тапшырган көннән исәпләнә.

39. Башкарма комитетның адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турындагы карары, шулай ук адрес бирү яки аны гамәлдән баш тарту турындагы карары гаризада күрсәтелгән ысулларның берсе аша Башкарма комитет тарафыннан гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) җибәрелә:

әлеге Кагыйдәләрнең 37 һәм 38 пунктларында күрсәтелгән срок чыкканнан соң бер эш көне эчендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән региональ порталдан яки адрес системасы порталыннан файдаланып, электрон документ формасында;

гариза бирүченең (гариза бирүченең вәкиленең) шәхсән үзенә расписка буенча кәгазь йөрткечтәге документ формасында биреп яисә документны, әлеге Кагыйдәләрнең 37 һәм 38 пунктларында күрсәтелгән срок чыккач, 10 эш көненнән соңгы көннән соңга калмый, гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча почта аша.

Гаризада адресация объектына адрес бирү турындагы карарны, адрес бирү яки гамәлдән чыгару турындагы карарны гариза бирү урыны буенча күп функцияле үзәк аша бирү турында күрсәтмә булган очракта, Башкарма комитет әлеге Кагыйдәләрнең 37 һәм 38 пунктларында билгеләнгән срок чыкканнан соң икенче эш көнендә гариза бирүчегә бирү өчен, документны күп функцияле үзәккә тапшыруны тәэмин итә.

40. Адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару түбәндәге очракларда кире кагылырга мөмкин:

1) адресация объектына адрес бирү турындагы гариза белән әлеге Кагыйдәләрнең 27 һәм 29 пунктларында күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать иткән очракта;

2) ведомствоара запроска җавап адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару өчен кирәкле документның һәм (яки) мәгълүматның булмавын раслаган һәм тиешле документ гариза бирүченең (гариза бирүченең вәкиленең) инициативасы буенча бирелмәгән очракта;

3) адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару өчен документлар (тапшыру өчен җаваплылык гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) йөкләнгән) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртипне бозып тапшырылган очракта;

4) әлеге Кагыйдәләрнең 5, 8-11 һәм 14-18 пунктларында күрсәтелгән адресация объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгаруга мөнәсәбәтле хәлләр һәм шартлар булмаган очракта.

41. Адресация объектына адрес бирүне яки аның адресын гамәлдән чыгаруны кире кагу турындагы карар, әлеге Кагыйдәләрнең 40 пунктында күрсәтелгән һәм әлеге карарны кабул итү өчен нигез булып торучы нигезләмәләргә мәҗбүри сылтамасы булган кире кагу сәбәбен үз эченә алырга тиеш.

42. Адресация объектына адрес бирүне яки аның адресын гамәлдән чыгаруны кире кагу турындагы карар формасы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

43. Адресация объектына адрес бирүне яки аның адресын гамәлдән чыгаруны кире кагу турындагы карардан риза булмыйча суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

## III. Адрес структурасы

44. Адрес структурасы идентификацияләүче реквизитлары (алга таба адрес реквизиты) белән тасвирланган адрес барлыкка китерә торган элементларның түбәндәге эзлеклелеген үз эченә ала:

1) илнең исеме (Россия Федерациясе);

2) Россия Федерациясе субъектының исеме;

3) торак пунктның исеме;

4) планлаштыру структурасы элементының исеме;

5) урам-юл челтәре элементының исеме;

6) җир участогының номеры;

7) бинаның, корылманың яки төзелеше тәмамланмаган объектның тибы һәм номеры;

8) бинада яки корылмада урнашкан бүлмәнең тибы һәм номеры.

45. Адресны тасвирлаганда, адрес структурасында адрес барлыкка китерә торган элементларның әлеге Кагыйдәләрнең 44 пунктында күрсәтелгән эзлеклелегенә туры килә торган адрес язуның билгеле эзлеклелеге файдаланыла.

46. Адресация объектының адресын тасвирлаганда файдаланылучы адрес барлыкка китерә торган элементларның исемлеге адресация объектының төренә бәйле.

47. Адресация объектларының барлык төрләре өчен мәҗбүри адрес барлыкка китерә торган элементлар булып түбәндәгеләр тора:

1) ил;

2) Россия Федерациясе субъекты;

3) торак пункт.

48. Башка адрес барлыкка китерә торган элементлар адресация объекты төренннән чыгып кулланыла.

49. Җир участогының адрес структурасы әлеге Кагыйдәләрнең 47 пунктында күрсәтелгән адрес барлыкка китерә торган мәҗбүри элементларга

өстәмә рәвештә, идентификацияләүче реквизитлар белән тасвирланган түбәндәге адрес барлыкка китерә торган элементларны үз эченә ала:

1) планлаштыру структурасы элементының исеме (булган очракта);

2) урам-юл челтәре элементының исеме (булган очракта);

3) жир участогының номеры.

50. Бина, корылма яки төзелеше тәмамланмаган объектның адрес структурасы әлеге Кагыйдәләрнең 47 пунктында күрсәтелгән адрес барлыкка китерә торган мәҗбүри элементларга өстәмә рәвештә, идентификацияләүче реквизитлар белән тасвирланган түбәндәге адрес барлыкка китерә торган элементларны үз эченә ала:

1) планлаштыру структурасы элементының исеме (булган очракта);

2) урам-юл челтәре элементының исеме (булган очракта);

3) бинаның, корылманың яки төзелеше тәмамланмаган объектның тибы һәм номеры.

51. Бина (корылма) чикләрендәге бүлмәнең адрес структурасы әлеге Кагыйдәләрнең 47 пунктында күрсәтелгән адрес барлыкка китерә торган мәҗбүри элементларга өстәмә рәвештә, идентификацияләүче реквизитлар белән тасвирланган түбәндәге адрес барлыкка китерә торган элементларны үз эченә ала:

1) планлаштыру структурасы элементының исеме (булган очракта);

2) урам-юл челтәре элементының исеме (булган очракта);

3) бинаның, корылманың тибы һәм номеры;

4) бина, корылма чикләрендәге бүлмәнең тибы һәм номеры;

5) фатир чикләрендәге бүлмәнең тибы һәм номеры (коммуналь фатирга карата).

52. Адрес реквизиты сыйфатында файдаланыла торган планлаштыру структурасы элементларының, урам-юл челтәре элементларының, бина (корылма) һәм бүлмә тибларының исемлеге, шулай ук адрес барлыкка китерә торган элементларның кыскартылган исемнәренең кагыйдәләре Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

## IV. Адресация объектларының исемнәрен язу һәм нумерацияләү кагыйдәләре

53. Адрес структурасында илнең, Россия Федерациясе субъектының, торак пунктның, планлаштыру структурасы элементларының һәм урам-юл челтәре элементларының исемнәре рус алфавиты хәрефләрен кулланып күрсәтелә. Планлаштыру структурасы элементларының һәм урам-юл челтәре элементларының өстәмә исемнәре латин алфавиты хәрефләрен кулланып, шулай ук Башкарма комитет ихтыяры буенча Россия Федерациясе субъектларының дәүләт телләренедә яки Россия Федерациясе халыкларының туган телләрендә күрсәтелергә мөмкин.

Торак пунктларның исемнәре Дәүләт географик атамалар каталогына кертелгән тиешле исемнәргә туры килергә тиеш.

Илнең һәм Россия Федерациясе субъектларының исемнәре Россия Федерациясе Конституциясендәге тиешле исемнәргә туры килергә тиеш.

Россия Федерациясе дәүләт муниципаль берәмлекләр реестры нигезендә Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге территорияләрнең, шәһәр һәм авыл җирлекләре исемнәренең исемлеге, Дәүләт географик атамалар каталогы нигезендә торак пунктлар исемнәренең исемлеге, дәүләт адрес реестрын алып барганда федераль мәгълүмати адрес системасы операторының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара ведомствоара мәгълүмати эшчәнлеге тәртибендә федераль мәгълүмати адрес системасы операторы тарафыннан Россия Федерациясе дәүләт муниципаль берәмлекләр реестры һәм Дәүләт географик атамалар каталогы буенча алынган мәгълүматлар нигезендә федераль мәгълүмати адрес системасына урнаштырыла.

54. Планлаштыру структурасы элементы һәм урам-юл челтәре элементы исемнәрендә рус алфавитының баш һәм юл хәрефләрен, гарәп цифрларын, шулай ук түбәндәге символларны куллану рөхсәт ителә:

1) «-» - дефис;

2) «.» - нокта;

3) «(» - ачылучы түгәрәк җәя;

4) «)» - ябылучы түгәрәк җәя;

5) «N» - номер билгесе.

55. Планлаштыру структурасы элементы һәм урам-юл челтәре элементы исемнәре хәзерге рус әдәби теленең сүз ясагыч, әйтелеш һәм стилистика нормаларына җавап бирергә тиеш.

56. Урам-юл челтәре элементының үз исеме составына керә торган тәртип саны, гарәп цифрлары кулланып һәм дефис аша грамматик кушымча хәрефе (хәрефләре) өстәп, урам-юл челтәре элементының исеме башында күрсәтелә.

57. Урам-юл челтәре элементының үз исемендәге истәлекле даталар хөрмәтенә бирелгән цифрларга, шулай ук иялек килешендәге тәртип санын белдерә торган цифрларга грамматик кушымча өстәлми.

58. Планлаштыру структурасы һәм урам-юл челтәре элементларының күренекле эшлеклеләр хөрмәтенә бирелгән үз исемнәре иялек килешендә рәсмиләштерелә.

59. Планлаштыру структурасы элементының һәм урам-юл челтәре элементының исем һәм фамилиядән торган үз исеме исем һәм фамилиянең баштагы хәрефләре белән алмаштырылмый. Балигъ булмаган геройлар хөрмәтенә бирелгән исемнәр исемнең кыскартылган варианты белән рәсмиләштерелә.

60. Планлаштыру структурасы элементларының һәм урам-юл челтәре элементларының исем һәм фамилиядән яки звание һәм фамилиядән торган состав өлеше исем һәм фамилияне яки звание һәм фамилияне тулысынча язып кулланыла.

61. Адресация объектларын нумерацияләү өчен адресация структурасында, хәреф индексы өстәп (кирәк булган очракта), бөтен һәм (яки) вакланмалы сан кулланыла.

Адресның номерлы өлешен формалаштырганда гарәп цифрлары һәм, кирәк булганда, «ё», «з», «й», «ъ», «ы» һәм «ь» хәрефләреннән, шулай ук «/» авыш сызык символыннан тыш, рус алфавиты хәрефләре кулланыла.

62. Урам-юл челтәре элементлары киселешендә урнашкан адресация объектларына адрес адресация объектының фасады карый торган урам-юл челтәре элементы буенча бирелә.

63. Эзлекле номерлы адреслар бирелгән ике адресация объекты арасында урнашкан адресация объектларын нумерацияләү, тиешле адресация объектына бирелгән кечерәк номерга хәреф индексы өстәп башкарыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова